# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 8 июлендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатларында түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партия – Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия, шулай ук "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 17 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандаты тапшырылган кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия. Кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия дигәндә, әлеге Закон максатларында республика бүлекчәсе кандидатлар исемлеген күрсәткән сәяси партия дип тә аңларга кирәк;

2) региональ телеканал – Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген яктыртканда әлеге Закон белән аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итү йөкләнгән "Татарстан – Яңа Гасыр" телевидениесе";

3) региональ радиоканал – Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген яктыртканда әлеге Закон белән аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итү йөкләнгән "Татарстан – Яңа Гасыр" радиосы";

4) теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешма – теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыру лицензиясенә ия булучы һәм региональ телеканалны һәм радиоканалны гамәлгә куючы "Яңа Гасыр" телерадиокомпаниясе" ААҖ.

2 статья. **Әлеге Закон предметы һәм аның гамәли өлкәсе**

1. Әлеге Закон белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртуга бәйле мөнәсәбәтләр җайга салына.

2. Әлеге Законның гамәли көче түбәндәгеләргә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагылмый:

1) федераль дәүләт хакимияте органнарына сайлаулар, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча сайлау кампаниясе, Россия Федерациясе референдумы, Татарстан Республикасы референдумы, җирле референдум кампаниясе башланган көннән алып күрсәтелгән сайлауларның, референдумнарның нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәрге чорда сәяси партияләр турында мәгълүмат, шулай ук күрсәтелгән кабат һәм өстәмә сайлаулар буенча сайлау кампанияләренә бәйле мәгълүмат алуга һәм таратуга гражданнар хокукларына гарантияләр тәэмин итүгә;

2) әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешенең 3 – 6 пунктларында күрсәтелгән депутатлар һәм фракцияләр эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру очракларыннан тыш, дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, башка дәүләт һәм муниципаль органнарның эшчәнлеген яктыртуга.

3 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртуның гомуми принциплары**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктырту түбәндәге гомуми принциплар нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) һәр партиянең эшчәнлеге турындагы мәгълүматны бертигез күләмдә тарату;

2) партияләр эшчәнлеген яктыртуга дәүләт контроленең гавамилеге;

3) партияләр эшчәнлеген яктыртканда региональ телеканал һәм радиоканал редакцияләренең иҗади бәйсезлеге һәм профессиональ мөстәкыйльлеге, мондый яктыртуның нигезләрен, рәвешләрен һәм ысулларын мөстәкыйль билгеләүне дә кертеп;

4) партия эшчәнлеге турында телевизор караучыларны һәм радио тыңлаучыларны һәрьяклап һәм объектив мәгълүмат белән тәэмин итү.

4 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләр эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртуга куела торган таләпләр**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеге региональ телеканал һәм радиоканал аша әлеге Закон таләпләрен исәпкә алып яктыртыла.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партиянең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктырту түбәндәгеләрнең эшчәнлеге турындагы мәгълүматны урнаштыруны күздә тота:

1) күрсәтелгән сәяси партиянең, аның җитәкче һәм башка органнарының, структур бүлекчәләренең, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектларындагылар да;

2) күрсәтелгән сәяси партиянең җитәкче органнары һәм аның структур бүлекчәләренең җитәкче органнары әгъзаларының, шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектларындагылар да;

3) күрсәтелгән сәяси партия төзегән фракциягә керүче Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларының йә күрсәтелгән сәяси партия тарафыннан чыгарылган, "Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында" 2005 елның 18 маендагы 51-ФЗ номерлы Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары (депутат мандаты) тапшырылган федераль кандидатлар исемлеге составында сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларының (депутатының);

4) Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарының күрсәтелгән сәяси партиянең депутат берләшмәләре (фракцияләре) әгъзалары булып торучы депутатларының йә күрсәтелгән сәяси партиянең "Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 17 пунктында каралган Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарында депутат мандатлары тапшырылган кандидатлар исемлекләре составында сайланган әлеге органнар депутатларының, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары депутатларының – күрсәтелгән сәяси партия әгъзаларының;

5) муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органының күрсәтелгән сәяси партиянең депутат берләшмәләре (фракцияләре) әгъзалары булып торучы депутатларының, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының – күрсәтелгән сәяси партия әгъзаларының;

6) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарында һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнарында күрсәтелгән сәяси партиянең депутат берләшмәләренең (фракцияләренең).

3. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 – 5 пунктларында күрсәтелгән затларның эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партия эшчәнлегенә бәйле булмаган мәгълүматны шул затларның тиешле сәяси партиягә каравын күрсәтмичә генә тарату әлеге Законның 5 статьясы нигезендә контрольдә тотылмый һәм исәпкә алынмый.

4. Әлеге статьяның 2 өлешендәге 2 – 5 пунктларында күрсәтелгән затларның мөрәҗәгатьләре һәм чыгышлары (мөрәҗәгатьләреннән һәм чыгышларыннан фрагментлар) телеканалда – титрлар белән, радиоканалда мондый затларның

Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы тиешле сәяси партиягә каравын күрсәтүче аңлатма характерындагы хәбәрләр белән алып барылырга тиеш.

5 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итүне тикшереп тору**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итүне тикшереп тору күрсәтелгән сәяси партияләр, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең массакүләм коммуникация өлкәсендә вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешма, шулай ук килешү буенча федераль башкарма хакимият органының массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә тикшереп тору һәм күзәтчелек итү функцияләрен гамәлгә ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партия эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртуга бер календарь ай дәвамында сарыф ителгән эфир вакыты күләмен исәпкә алып бару тәртибе һәм методикасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән раслана. Эфир вакыты күләмен исәпкә алып бару методикасында әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат булган хәбәрләрнең саны, мондый хәбәрләрнең дәвамлылыгы, шулай ук әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешенең 2 – 5 пунктларында күрсәтелгән затлар мөрәҗәгатьләренең һәм чыгышларының (мөрәҗәгатьләреннән һәм чыгышларыннан фрагментларның) гомуми хронометражы кебек күрсәткечләр күздә тотылырга тиеш. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәр сәяси партиянең эшчәнлеген яктыртуга сарыф ителгән эфир вакытының күләмен исәпкә алып бару тәртибенә һәм методикасына башка таләпләр дә расланырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген яктыртуга бер календарь ай дәвамында сарыф ителгән эфир вакыты күләмен исәпкә алып баруның нәтиҗәләрен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе эшче төркем төзи. Эшче төркем составына Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасы, күрсәтелгән сәяси партияләрнең һәркайсыннан, теле- һәм радио тапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмадан, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә вәкаләтле органыннан, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасыннан берәр вәкил керә. Эшче төркем составына килешү буенча Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вәкиле, федераль башкарма хакимият органының массакүләм мәгълүмат чараларын тикшереп тору һәм күзәтчелек итү функцияләрен гамәлгә ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы буенча территориаль органы вәкиле,

башка белгечләр керергә мөмкин. Эшче төркем эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы җитәкчелек итә. Эшче төркем эшчәнлегенең тәртибе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

4. Теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешма Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртуга сарыф ителгән эфир вакыты күләмен әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән тәртип һәм методика нигезендә исәпкә алып баруны кертергә тиеш.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген яктыртуга сарыф ителгән эфир вакыты күләмен исәпкә алып бару шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән тәртип һәм методика нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген бер календарь ай дәвамында тигез күләмдә яктырту турындагы таләпне бозу фактын билгеләгән очракта, ул тиешле сәяси партиягә карата эфир вакытының җитешмәгән күләмен компенсацияләү зарурлыгы турында карар кабул итә һәм күрсәтелгән карарны теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмага җибәрә. Әгәр эфир вакытының җитешмәгән күләмен тиешле сайлау кампаниясе, референдум кампаниясе башланган көннән алып сайлаулар, референдум нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгарган көнгә кадәрге чорда гына компенсацияләү мөмкин булса, мондый карар сайлаулар, референдум нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң кабул ителә.

7. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән карарын алган теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешма Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы тиешле сәяси партиягә карата телеканалда яисә радиоканалда эфир вакытының җитешмәгән күләмен, әлеге статьяның 8 өлешендә каралган очрактан тыш, карар алган көннән алып 30 көн эчендә компенсацияли.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән карары белән килешмәгән очракта, теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешма аны алган көннән алып 10 көн эчендә бу хакта язма рәвештә, мондый килешмәүнең сәбәпләрен дәлилле нигезләп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итәргә хокуклы.

9. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе хәбәрнамәне алган көннән алып 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген яктыртуга тиешле календарь ай эчендә сарыф ителгән эфир вакыты күләмен исәпкә алып бару нәтиҗәләре турындагы мәсьәләне кабат карый. Әгәр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе сәяси партияләр эшчәнлеген тиешле күләмдә яктырту турындагы таләпне бозу фактын кабат билгеләгән карар кабул итсә, теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешма мондый карар кабул ителгән көннән алып 20 көн эчендә тиешле сәяси

партиягә карата тиешле телеканалда яисә радиоканалда эфир вакытының җитешмәгән күләмен компенсацияли.

10. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарыннан, теле- һәм радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмадан әлеге Закон белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү өчен кирәкле белешмәләрне һәм материалларны соратып алырга хокуклы.

11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген узган календарь елда региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итү турындагы белешмәләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан "Республика Татарстан" һәм "Ватаным Татарстан" газеталарында ел саен агымдагы елның 31 гыйнварыннан да соңга калмыйча бастырып чыгарыла.

6 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслау**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы сәяси партияләрнең эшчәнлеген региональ телеканал һәм радиоканал аша яктыртканда аларның тигезлек гарантияләрен тәэмин итүгә бәйле, шул исәптән әлеге гарантияләрнең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итүгә бәйле, чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон, 2011 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 4 статьясыннан, 5 статьясының 1, 4, 6 – 10 өлешләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 30 июле
№ 59-ТРЗ